СӨТ ХАКЫ

«ВТ» хәбәрчесе сөт бәяләрен белеште

> 2

МАТУРЛЫК БӘЙРӘМЕ

Татарстан гүзәлләренең йөзенә дә, эчке дөньясына да таләпләр зур

> 3



ЯЗУЧЫ СҮЗЕ

«Яшәү дәрәҗәсен муллык кына билгеләми»

> 4

ГАМЬЛЕ ЮЛ

Айдар Фәйзрахманов яңа китабын тәкъдим итте

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 15 (28982) | Чәршәмбе | 1 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ҮЗӘКТӘ – ШӘХЕС

Йомгак

Мәдәният ул – биналар һәм таш диварлар гына түгел. Аның иң мөһим өлеше – кеше, шәхес. Татарстан Мәдәният министрлыгының йомгаклау утырышында әйтелгән төп фикер әнә шул булды.

«Татар-информ»

Билгеле булганча, 2023 ел Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Аны Илһам Шакиров исемендәге Зур концерт залында Сабан туе күренешләре белән башлап җибәрделәр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исә бу елга юнәлеш бирде. Аның сүзләре белән әйтсәк, 2023 ел милли колоритны популярлаштыру өчен этәргеч булырга тиеш.

– Әлеге мәсьәлә актуальлеген беркайчан да югалтмаячак. Буыннан-буынга күчеп килгән рухи хәзинәләрне, туган телне, гореф-гадәтләрне, тарих һәм мәдәни мирасны өйрәнүгә һәрвакыт тиешле игътибар бирергә кирәк. Сүздә генә түгел! Һәм бу эшне активистларга гына аударып калдырмаска кирәк, – диде ул.

Тармак эшчәнлегендәге узган елгы төп нәтиҗәләр хакында Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова сөйләде. Күп юнәлешләрдә республика – алдынгы урыннарда, ләкин игътибарга аласы мәсьәләләр дә җитәрлек. Шулай да мисалны яхшысыннан китерик. Узган ел Татарстандагы мәдәният учаклары 73,5 млн кеше кабул иткән. План 14,5 процентка арттырып үтәлгән. Бу юнәлештә Татарстан Россия буенча 6 нчы урында булса, Идел буе федераль округы төбәкләре арасында – 2 нче урында.

Мәдәният министры быел да «Пушкин картасы» проектына аерым тукталды. Узган ел әлеге проект кысасында мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә билет сату буенча Мәскәүне уздырып булмаса да, Татарстан – алдынгылар рәтендә. Ютазы, Тәтеш һәм Спас районнары тагын да активрак эшләсә, кем белә бит, киләсе елга беренче дә булырбыз әле.

– Әлеге проект барыннан да элек яшь буынны тәрбияләү өчен кирәк. Дәүләт һәм муниципалитет учреждениеләре җитәкчеләреннән сәхнәне уйлап кына бирүләрен үтенәм. Чөнки сәхнәгездә алып барылган программалар өчен сез җаваплы, – дип кисәтте Ирада ханым.

Авылларга кайтып килик. 2012 елдан бирле Татарстан авылларында 343 мәдәният йорты төзелгән, 289ында ремонт булган.

– Авылларда тормышны яхшыртуга зур игътибар бирелә. Яраксыз хәлдәге мәдәният йортларының саны елдан-ел кими. Шулай булуга карамастан, кайбер районнарга сорауларыбыз бар. Әйтик, 2012 елда Азнакайда өч мәдәният йортына ремонт кирәк булса, хәзер аларның саны – сигез. Шул ук вакытта районда төзелгән һәм төзекләндерелгән клубларның саны – 14. Мондый очраклар җитәрлек. Мәдәният йортларын карап тоту һәм файдалану мәсьәләсенә әле кат-кат әйләнеп кайтачакбыз, – диде Ирада Әюпова.

Моннан тыш ул яңа гына төзелгән яки ремонт эшләре тәгәлләнгән, барлык уңайлыклары да булган мәдәният учреждениеләренә йөрүчеләрнең саны артмауга басым ясады. Уңай мисаллар да китерде, билгеле. Әйтик, ремонттан соң эшли башлаган Чаллы театры, Казан циркы, Милли китапханә бу җәһәттән яхшы нәтиҗәгә ирешкән. Ә менә Түбән Кама театрында бөтенләй дә үсеш булмаган.

Йомгаклау утырышында күршеләр белән дуслыкның әһәмияте турында да сүз чыкты. Чарага Россиянең сигез төбәгеннән мәдәният министрлары килгән иде. Ирада Әюпова аларга хезмәттәшлек өчен рәхмәтен белдерде һәм киләчәктә тә бергә-бергә эшләргә чакырды. Мондый хезмәттәшлекнең нигезендә тәҗрибә уртаклашу ята, шуңа да әһәмиятле ул.

Ләкин мәдәният ул – биналар һәм таш диварлар гына түгел. Ирада Әюпова сүзләренчә, бу тармакның үзәгендә – кеше, шәхес.

– Безнең бурыч – һәркемгә үз сәләтен күрсәтер өчен шартлар тудыру. Ләкин бу эшне остазлардан башка күз алдына китереп булмый. Бу җәһәттән белем бирү системасына аерым тукталырга кирәк. Хәзерге вакытта мәдәният тармагында 22 меңнән артык кеше эшли. Тик районнарда һәм авылларда белгечләр җитмәү мәсьәләсе әле дә хәл ителми, – диде мәдәният министры.

Хәзерге вакытта әлеге мәсьәләне хәл итүнең берданбер юлы – максатчан укыту программасы. Бүген Мәдәният институтында 315 студент әлеге программа буенча белем ала. Ләкин соңгы өч ел эчендә авылга кайтып эшкә урнашканнан соң бер тапкыр бирелә торган түләүне бары бер кеше генә алган.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов мәдәният министры күтәргән мәсьәләләрнең һәркайсына карата үз фикерен җиткерде. Беренче эш итеп, мәдәни инфраструктурага тукталды.

– Мәдәният учреждениеләре төзелеп һәм төзекләндерелеп тора. Ләкин монда бит ремонт һәм матур диварлар мөһим түгел. Буш тормасын алар! Халыкның рухи һәм мәдәни үсешенә хезмәт итсеннәр. Бу мәсьәләдә иң мөһиме – кадрлар. Кирәк нәрсәне сатып алырга, төзергә була. Ләкин яхшы белгечләрсез нәтиҗә булмаячак. Министр телгә алган театр (Түбән Кама театры. – **Авт.**) – шуңа мисал, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул шулай ук илкүләм «Пушкин картасы» проекты хакында да әйтте. Башта икеләндерсә дә, соңыннан үзен тулаем аклады, дип аңлатты Президент:

– Бүген әлеге яхшы мөмкинлектән тиешле дәрәҗәдә файдаланмый торган районнар аталды. Әлеге мәсьәләгә игътибар итүегезне сорыйм. Ул турыдан-туры киләчәк буынны тәрбияләүгә барып тоташа.

Рөстәм Миңнеханов Мәдәният министрлыгы эшчәнлегенә шелтә белдермәде. Уенын-чынын бергә кушып: «Билгеле, йомшак якларыбыз аз түгел. Ләкин Мәскәүдән килгән кешеләр мактады үзегезне. Шуңа күрә бүген тәнкыйтьләмим, фикерләремне җиткерүнең башка юлларын табарбыз», – диде.

Сан

2022 елда республикада мәдәни тармак буенча бюджеттан тыш керемнәр күләме **1,8** млрд сумны тәшкил иткән. Моның **563,1** млн сумы районнарга туры килә. Мәдәни тармакта акчаны иң яхшы эшләүче районнар – Тәтеш, Түбән Кама, Яшел Үзән, Әлмәт.

Солдат киемен салганнар

Өлешчә мобилизация барышында хәрби хезмәткә чакырылган 9 меңнән артык кешене өйләренә кайтарып җибәргәннәр. Алар арасында сәламәтлеге начар булу сәбәпле мобилизациягә эләкмәскә тиешлеләр дә бар. Россия Генераль прокуроры Игорь Краснов Президент Владимир Путинга шул хакта әйткән.

Прокурор әйтүенчә, махсус хәрби операция үткәрү чорында кораллы көчләр һәм илнең оборона-сәнәгать комплексында законнарның үтәлешен контрольдә тоту эше нык көчәйтелгән. Ул шулай ук хәрби хезмәткә чакырылучыларны бронежилетлар, башка кирәк-ярак белән тәэмин итү проблемасының тулысынча хәл ителүен дә искәрткән. Хәзер прокуратура хәрбиләргә кышкы кием җибәрүне контрольдә тота икән.

Иң бай министрлык

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы узган елда түләүле хезмәтләр күрсәтүдән барлык оешмалардан да күбрәк – 5,36 миллиард сум акча керткән. Финанс министрлыгы хисабыннан күренгәнчә, кереме буенча икенче урынга Мәгариф һәм фән министрлыгы чыккан (1,3 миллиард сум). Ведомство карамагындагы һөнәри белем оешмалары барыннан да уздырган – 1 миллиард сумнан артыграк күләмдә керем алган. Мәдәният министрлыгы 1,1 миллиард сумлык акча эшләгән. Ведомствога театр-концерт учреждениеләре 832,3 миллион сум күләмендә керем китергән. Кинотеатрлар исә – нибары 10,9 миллион сум гына.

Урман хуҗалыгы министрлыгы 831,37 миллион сум акча эшләгән. Министрлыкка урман хуҗалыклары – 827,9 миллион сум, урман янгыннарын сүндерү үзәге 1,2 миллион сум керткән.

Ә менә Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы түләүле хезмәтләр күрсәтү буенча барыннан да азрак акча эшләгән (629,5 мең сум). Керемне аңа Умартачылык идарәсе китергән. Икътисад министрлыгының да бу яктан мактанырлыгы юк – нибары 1,6 миллион сум.

Тарихны яңача укыячаклар

Илдар Мөхәммәтҗанов

Махсус хәрби операция турындагы бүлекне үз эченә алачак тарих дәреслеге быел ук сынап каралачак, ә 2024/2025 уку елында инде барлык мәктәпләргә кертеләчәк. Россия Мәгърифәт министрлыгы хәбәр иткәнчә, яңа дәреслекне тарихчылар, социолог, психологларның тулы бер командасы төзи. «Укучылар ил, дөнья хәлләре белән даими кызыксына, сорауларына җавап эзли. Укытучылар аларга дөрес мәгълүматлар табарга ярдәм итәргә тиеш. Юкса балалар җавапны мәгълүмат сугышы барган, ялган хәбәрләр белән тулган урыннарда табачак. Шуңа күрә хәзер «Мөһим сөйләшү» дәресләренә зур ихтыяҗ туды да», – дигәннәр министрлыкта.

Исегезгә төшерәбез: мәгърифәт министры Сергей Кравцов өлкән сыйныф укучылары өчен махсус хәрби операция темасын үз эченә алган яңа дәреслекнең март аенда әзер булачагын белдерде. Аның әйтүенчә, тарих буенча курс программасында хәрби операциянең максатлары һәм бурычлары турында бүлек урын алган да инде. Ә яңа дәреслектә бу җәһәттән тәфсиллерәк мәгълүматлар биреләчәк.

Яңалык

Февраль үзгәрешләре

Иң әһәмиятлеләрен тәкъдим итәбез

☑ Түләүләр һәм пособиеләр күләме арта. 1 февральдән мөһим социаль пособиеләр, шул исәптән айлык акчалата түләү (ЕДВ) күләме 11,6 процентка үсә. Исегезгә төшерәбез: ЕДВ Бөек Ватан сугышы ветераннарына, инвалидларга, шул исәптән инвалид балаларга һ.б. бирелә. Моннан тыш 40тан артык компенсация һәм пособие күләме индексацияләнә. Әйтик, бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие (20,4 мең сумнан 22,9 мең сумга җитә), бала карау өчен айлык пособие (минималь күләме 7679 сумнан 8591 сумга җитә), ана капиталы арта. Ана капиталы беренче балага алынмаган булса, икенчесе туганда 775,6 мең сум (моңа кадәр 693,1 мең сум булган) биреләчәк. Ә инде беренче балага алынган очракта – 188,7 мең сум (168,6 мең сум булган).

☑ Көнбатыш илләре тарафыннан нефтьнең чик бәясен кертүгә җавап чаралары «эшли» башлаячак. Президентның бу җәһәттән имзаланган Указында, контрактта турыдан-туры яки читләтеп чик бәя куллану күздә тотылган очракта, чит илләргә Россия нефтен, нефть продуктларын сатуның тыелуы каралган.

☑ Интернетның начар эшләве өчен штраф сала башлаячаклар. Мондый очракларда элемтә операторлары, технологик челтәр хуҗалары җавапка тартылачак. Штраф күләмнәре болайрак: вазыйфаи затларга – 5 меңнән 10 мең сумга кадәр, хосусый эшмәкәрләргә – 10 меңнән 20 мең сумга кадәр, юридик затларга – 30 меңнән 50 мең сумга кадәр.

☑ Запастагы хәрбиләр өчен тәгаенләнеп тә, моңарчы буш торган торакны ташламалардан файдаланучыларга бирү рөхсәт ителә. Мондый закон 4 февральдән үз көченә керә. Моңа кадәр хәрбигә билгеләнгән торак, әйтик, милекченең вафат булуы, торактан баш тартуы яки башка җиргә күченүе сәбәпле, буш торган. Төбәкләр аны үз хисабына тоткан, торакны мохтаҗларга тапшыру тыелган. Менә хәзер мондый фатирларны Бөек Ватан сугышы ветераннарына, аларның гаиләләре әгъзалары, Чернобыль АЭСындагы фаҗиганең аянычлы нәтиҗәләрен бетерүчеләр, инвалид балалы гаиләләр, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына бирергә мөмкин булачак.

☑ Яшәү өчен мөһим дарулар исемлегенә 28 февральдән яңа препаратлар кертелә. Болар – «Рамиприл» (йөрәк авыруыннан), «Цефотаксим+сульбактам» (бактерияләргә каршы), «Пэгаспаргаза» (балаларда лейкоз авыруын дәвалау өчен) һ.б. Шул ук вакытта «Мельдоний» исемлектән төшереп калдырылган. Исемлек дару бәяләрен дәүләт тарафыннан көйләү, ташламалардан файдаланучыларның аларны бушлай алуы өчен төзелә. Хәзерге вакытта аңа 800дән артыграк дару керә. Алар арасында яман шеш авыруларыннан, шикәр чире, бронхиаль астма, В гепатитыннан препаратлар бар.

☑ Дәүләт хезмәтләре порталына логин һәм пароль белән генә түгел, ә бердәм биометрия системасы (ЕБС) белән керү мөмкинлеге дә барлыкка киләчәк. Бу – ихтыяри гамәл. ЕБСда теге яки бу банк бүлегендә теркәлергә була. Моның өчен банкның клиенты булып тору мәҗбүри түгел. Оешма хезмәткәре сезне фотога төшереп, тавышыгызны яздырачак һәм Дәүләт хезмәтләрендә теркәячәк. Теркәү өчен 5 көнгә кадәр вакыт таләп ителә.

☑ Салым хезмәте яңача эшли башлый. Хәзерге вакытта салым түләүченең шәхси кабинетына ия булучыларга салым түләргә кирәклек турында хатлар җибәрелми. 1 февральдән, шәхси кабинетка ия булу-булмавыгызга карамастан, салым органыннан хатлар килә башлаячак.

Сүзгә-сүз

Михаил МУРАШКО, Россия сәламәтлек саклау министры:

Коронавируска каршы көрәш буенча чараларны гамәлгә ашыру, медицина ярдәмен оештыру алымнарын камилләштерү һәм заманча эш алымнарын куллану, чиргә бәйле вазгыятьне тотрыкландыруга, икенче яртыеллыкта үлүчеләр санын киметүгә һәм гомер озынлыгын арттыруга ирешергә мөмкинлек бирде. Күрсәткеч 2,5 елга артты.

РОССИЯДӘ – АКЧА

«Открытие» банкы һәм «Росгосстрах» компаниясе Россиядә яшәүчеләрдән хыялдагы керем дәрәҗәсе турында сорашкан.

(АЕНА)

42% >> 50–100 мең сум

22% >> 100–150 мең сум

8% >> 150–200 мең сум һәм аннан да күбрәк

2% >> 30 мең сум да җитә

71 кеше чирләгән

Соңгы тәүлектә Татарстанда коронавирус йоктыруның 71 яңа очрагы теркәлгән. 40 кеше хастаханәгә озатылган. Инфекциягә каршы көрәш буенча федераль оператив штаб хәбәренә караганда, республикада пандемия башланганнан бирле чир ияртүнең барлыгы 195233 очрагы ачыкланган. 192225 кеше савыккан, шуның 42се – соңгы тәүлектә. Инфекция Татарстанда барлыгы 2010 кешенең гомере өзелүгә китергән. Соңгы тәүлектә үлем-китем булмаган. Ил күләмендәге саннарга килгәндә, Россиядә бер тәүлектә 5792 кешедә коронавирус ачыкланган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЧИПЛАР ТҮНТӘРЕЛЕШЕ

Дөнья икътисадында глобаль кризис дигән куркыныч чирнең билгеләре торган саен күбрәк күренә. Бу атнада өч зур финанс үзәге – ФРС, Европа Үзәк банкы һәм Англия банкы төп ставкаларны соңгы 15 елдагы иң югары дәрәҗәгә җиткерергә ниятли. Процент ставкасын ни өчен күтәрүләрен белабез бит инде: инфляциягә каршы көрәшабез, диләр.

2023тән 15не алсак, 2008 елга килеп төшәбез. Хәтерлик әле: ул елда зур кризис аваз биргән иде. Бәясе 150 долларга җиткән баррель түбәнгә очты, фонд базарлары җимерелде, акчасыз калган миллиардерлар поезд астына ташланды... Былел хәл ул чактагыдан хәтәррәк, чөнки ставканы күтәрмәгән килеш тә рецессия тәгәрмәче әйләнә иде. Без анда Россия нефтен чикләүләргә карамастан, «кара алтын» бәясенең чагыштырмача түбән бәядә торуыннан, төп капиталистик илләрдә җитештерү түбәнәю турындагы статистика мәгълүматларыннан күрә алабыз. Соңгысы, статистика, бер дә күңелле саннар ирештерми. Германия икътисадында IV квартал нәтиҗәләре буенча күрсәткечләр түбән, ягъни җитештерү кимегән. Корьян яндырып, дөньяга мәшһүр булган шведларда да әчке тулай продукт нык кимеп бара. Испаниядә инфляция котырына. Кредитлар кыйммәтләнгәч, җитештерү артыр дип уйлыйсызмы? Юк, болай да егылып барган фонд базары түбәнгәрәк сикерәчәк. Инфляция кимер, бәлки, әмма дефляция белән рецессия икесе бергә җитәкләшеп йөрерләр.

Глобаль түнтәрелешне бу юлы ярымүткәргечләр җитештерү тармагы әйдәп бара. Чип җитештерүче компанияләрнең акцияләре кызу темплар белән очсызлана. Хәтер микросхемалары җитештерүче Америка компаниясе Micron декабрьдә яңа җиһазлар сатып алу өчен акчаны киметте, җитештерүне дә түбәнәйтәчәген игълан итте. Чиплар җитештерү өчен җиһазлар ясаучы Lam Research заказларның тиңсез дәрәҗәдә кимүен игълан итте. Корпорациянең генераль директоры Тим Арчер мондый хәлнең егерме биш ел буе күрелмәвен әйтә. Тагын арифметик исәпләүләр башкарыйк әле. 1998 елга килеп төшәбез, зур кризис чорына. Ул чакта кризис Азия базарларын һәм Россияне тетрәткән иде. Чип җитештерүче компанияләрнең саудәсе 30–50 процентка кими. Бу – нормаль булмаган вазгыять, дип чаң суга белгечләр.

Чиплар нигездә Азиядә җитештерелә. Американың хәрби өлкәдә кулланыла торган югары технологияле чипларының 90 процентын TSMC компаниясе җитештерә. Ул Тайваньда урнашкан. Америкаиннар үзләрендә 10 нанометрдан да кечерәк яңа буын чиплар җитештермиләр, Тайваньнан алалар. Тайвань мәсьәләсе буенча ни өчен Кытай белән Американың ут ягып талашуларын шуннан аңларсыз.

Ярымүткәргечләр базарындагы түнтәрелешне АКШның Кытайга керткән санкцияләре дә тәэмин итә. 14 декабрьдә Вашингтонда 30 чин компаниясен санкцияләр исемлегенә кертканнәр иде. Аларга чипта, чип җитештерү өчен кирәкле җиһазлар да сатмыйлар. Зыянны кем күрә дип уйлыйсыз? Базарлары тарайган Америка компанияләре. Бик күп объектив һәм субъектив сәбәпләр югары технологияле компанияләрне упкынга этәрен һәм глобаль икътисадны да инде.

Россиядә

БАЛАСЫЗЛЫК БӘЛАСЕ

Илкүләме җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге сораштырулары 18 яшьтән 45 яшькә кадәрге хатын-кызларның 48 процентының якындагы биш елда бала табуны планлаштырмавын, 7 процентының исә бөтенләй бала табарга теләмәвен күрсәтә. Саннар шомлы, демографик кризисның гадәттән тыш зур дәрәҗәсен вәгъдә итә. Илдә халык саны болай да зур темплар белән кими. 2013, 2014, 2015 елларда гына россиялеләр сан ягыннан үскән. Әйтик, 2014 елда 30 мең 336га артканбыз. Әмма 2017 елдан башлап кимүнең куркыныч саннары күзәтелә. 2017дә – 135 меңнән артык, 2018дә кимү саны – 224 мең 556, 2019да – 317 мең 233, пандемия башланган 2020 елда – 702 мең 072.

Үлем-китемнәр саны да соңгы елларда рекордлы. 2021 елда үлүчеләр саны 2020 елдагы белән чагыштырганда 15 процентка арткан. 2022 ел мәгълүматлары әле чыгып җитмәде, әмма беренче яртыеллыкта халык саны 480 меңгә кимү хакында Росстат мәгълүматлары бар. Елга күчергәч, миллионга якын сан күренәчәк. Мондый шартларда бала туунын кискен кимүе ил өчен куркыныч. Президент Владимир Путин куптән түгел генә, балалар санын арттыру өчен, иле атна эчендә чаралар уйларга күрсәтмә бирде бирүен, әмма бу андый җиңел мәсьәлә түгел.

Хатыннарның бала табу теләген махсус хәрби операция һәм өлешчә мобилизация дә нык киметкән икән. Ирләрне хәрби хәрәкәтләргә алырлар да, бала тотып, ялгыз калырбыз, дип уйлый күпләр. Тормышның матди шартлары начарао да үз сүзен әйтә. Монысы да – санкцияләр һәм махсус хәрби операция йогынтысы бит әле. Росстат ике никакха өч аерылышу туры килгәнне белдерә. Бала табу коэффициентын кимегүгә бу да үзенең зур өлешен кертә. Гаилә торгыксызлыгы шартларында баласын ялгыз үстерәсе килмәгән хатыннарга ни дип әйтәсең?

Үткән елның беренче 11 аенда Татарстанда һәм Идел буе федераль округында хәл мондыйрак. Татарстанда бала табу күрсәткече 10,6 процентка кимегән. Барысы 33511 бала туу теркалгән. Бу – федераль округтагы иң зур күрсәткеч. Өч төбәк бала туу санының кимү проценты буенча безнең республикага якын торып киткән. Киров өлкәсендә яңа туган балалар саны 12,2 процентка кимегән, Мари Илендә – 11,5, Удмуртиядә – 11,2 процент. Мари Илендә туган балалар саны 5325 кенә, Удмуртиядә – 11695. Иң аз бала Мордовиядә туган – 4321.

Саннарның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен чагыштырып карап кына белеп була. 1991 елда Татарстанда 51 мең 068 бала туган. 1992 елда – 44589. 2011 елда – 51391.

ПРЕЗИДЕНТНЫ КЕМ КЫЗЫКТЫРДЫ?

121 миллиард сум. Узган ел «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ берләштерелгән бюджетка әнә шулкадәр акча күчергән. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 40 процентка үскән. Алга таба республиканың нефть һәм газ химиясе тармагы предприятиеләренә эш тагын да артырга мөмкин.

tatarstan.ru

Хөкүмәт йортында «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ Директорлар советы утырышы узды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашты. Генераль директор Рафинат Яруллин сүзләренә караганда, былтыр республиканың нефть һәм газ химиясе комплексы предприятиеләре җитештерү күрсәткечен 1,8 процентка арттырган.

– Бу нефть чыгару, нефть продуктлары, ашламалар һәм полиолефиннар чыгару күләмен арттыру хисабына тәэмин ителде, – диде ул.

Урамда ни булса, өйдә шул дигәндәй, узган елның беренче яртысында дөньяда нефть, мотор ягулыгы, күпчелек химия продуктларына бәяләр арткан, ә елның икенче яртысында исә аларның кимүе күзәтелгән. Илдә дә хәлләр моңа охшаш, диделәр. 2022 елда республиканың нефть һәм газ химиясе тармагы предприятиеләре кайбер инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны тәгәлләгән. Аерым алганда, ТАНЕКО тәҗрибә рәвешендә ароматика җитештерүне башлап җибәрде, «Алабуга» махсус икътисадый зонасында көнкүреш пластмасса эшләнмәләрен ясауны җайга салдылар. Заманасына күрә импортны алмаштыру юнәлешендә дә тырышып эшлиләр. Рафинат Яруллин чит илдән кертелүче химия продукциясе, резина һәм пластмасса эшләнмәләрнә алмаш мәсьәләсендә мөмкинлекләрне уңай бәяләде. Шулай ук ул Россия икътисады ихтыяҗлары өчен ил технологияләрен һәм җиһазларын үстерү зарурлыгын да билгеләп үтте.

Утырышта инновацияле проектлар турында да сөйләштеләр. «ОКБМ Африкантов» АҖ генераль директорының беренче урынбасары Виталий Петрунин республика предприятиеләрен урак хезмәттәшлеккә өндәде. Баксаң, эшне җәелдерү өчен ил төбәкләрен өйрәнгәннәр һәм арадан Татарстанга өстенлек биргәннәр икән. «Росатом»да атом энерготехнология станцияләрен эшлиләр. Бирелдә зур күләмдә водород җитештереләчәк. Чиста водород алу өчен экологик яктан куркынычсыз ысуллар кулланыла», – дип сөйләде беренче урынбасар.

– Без әлеге темаңы ун елдан артык элек күтәргән идек, – диде Рөстәм Миннеханов. – Зур планнарыбыз да бар. Бу юнәлештә эшне дәвам итәргә кирәк.

Төбәкара эксперт-аналитика үзәге (Мәскәү) башкарма директоры Анатолий Замрий сыекландырылган табигый газ җитештерүнең заманча технологияләре турында сөйләде. Аның әйтүенчә, сыекландырылган табигый газ ерак төбәкләрне газлаштыру һәм газ-мотор ягулыгы буларак куллану өчен бик тә отышлы.

– Әлеге эш Татарстан өчен дә кызыклы булачак дип саныйбыз, – диде башкарма директор. – Монда машина төзелеше яхшы үсеш алган. Әлегә бездә газны сыекландыруның нәтиҗәле технологияләре юк. Алар барысы да Көнбатыш компанияләренә карый. «Татнефтехиминвест-холдинг»ны һәм республиканың машина төзелеше предприятиеләрен хезмәттәшлеккә җәлеп итәсе килә.

Президент әйтүенчә, бу – кызыктырылык тәкъдим. «Республикада РАРИТЭК һәм КАМАЗ бу мәсьәлә белән җитди шөгыльләнәләр», – диде Рөстәм Миннеханов.

Кичә Хөкүмәт йортында Президент Абхазия вице-премьеры, икътисад министры Кристина Озган белән дә очрашты. Билгеле булганча, чит ил делегациясе Казанга эш визиты белән килде. Алар Татарстан Икътисад министрлыгында очрашулар уздырдылар, шулай ук Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгында булдылар, бирелдә республиканың инвестиция проектлары белән таныштылар.

«Безне бик тәэсирләндек», – диде Кристина Озган һәм Татарстанның төрле юнәлешләр буенча тәҗрибәсен өйрәнү мөмкинлекләре өчен рәхмәт әйтте. Ул Абхазия Президенты Аслан Бжаниянең 2022 елда Татарстанга килүен дә искәртте. Рөстәм Миннеханов, үз чиратында, Татарстан белән элемтәләрне үстерү өлкәсендә кызыксынулары өчен рәхмәт белдерде.

– Татарстанның Абхазия белән мөнәсәбәтләре күптәнге һәм аның тарихы бар, – диде Президент. – 1994 елның августында безнең республикалар арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Татарстан белән Абхазия арасында товар әйләнеше зур булмаса да, уңай якка үзгәреш бар.

Яклар гамәлдәге уртак проектлар һәм хезмәттәшлекне тагын да үстерү турында фикер алыштылар.

Заманына күрә табибы

Казан дәүләт университетында хәрби хирургия һәм терапия курсы укытыла башлый. Мәктәп укучылары республикадагы хастаханәләр эшчәнлеге белән якыннан таныша алачак. Бер ел эчендә Татарстанда эшләүче медицина хезмәткәрләре саны арткан. Республиканың сәламәтлек саклау тармагындагы кадрлар мәсьәләсенә багышланган матбугат очрашуында шул хакта сөйләделәр.

Беренче сентябрьдән Казан дәүләт медицина университетында хәрби хирургия һәм терапия курсы укытыла башлаячак. Университет ректоры Алексей Созинов сүзләренә караганда, хәзерге вакытта университетта хәрби кафедра ачу турында да сөйләшүләр бара.

«Бүген хәрби-кыр хирургиясе, хәрби-кыр терапиясе курсы буенча программа эшләнә. Документлар әзер. Быелның 1 сентябреннән ул югары белем алучыларны укыту модуленә кертелер дип уйлыйбыз. Ул совет чорында ук бар иде бит», – ди ректор.

Әлеге яңалык республиканың сәламәтлек саклау өлкәсендәге юнәлешләрне дә, хезмәткәрләр санын да арттырыр дип көтелә. Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Илдар Фатыйхов сүзләренә караганда, республиканың сәламәтлек саклау тармагында эшләүче хезмәткәрләр саны ел эчендә арта бара. Бер ел эчендә бу тармакта эшкә урнашучылар саны 1 меңгә арткан. Узган ел нәтиҗәләре буенча республикада 10 мең кешегә – 35,9 табиб, 95,5 урта медицина хезмәткәре туры килә.

Бүген республикада барлыгы 56 меңләп медицина хезмәткәре исәпләнә. Шуларның 13 меңе – табиб. Чагыштыру өчен: 2021 елда аларның саны 2110 булган. «2024 елга хастаханәләрнең медицина хезмәткәрләре белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен 95 процентка җиткерү күздә тотыла. Әлегә бу күрсәткеч – 93,6 процент», – ди министр урынбасары.

4–15 февральдә Татарстанда унберенче тапкыр узачак «Ак халатлы фәрештәләр» фестивале да иң беренче чиратта әнә шул максатны күздә тота. Аның кысасында мәктәп укучылары белән студентлар республиканың барлык район хастаханәләре, иң яхшы дәвалау оешмалары белән танышып чыгачак. Ул көн дәвамында медицина, социаль темаларга багышланган дәресләр узачак. Моннан тыш әлеге фестивальдә «Иң акыллы табиб» дип исемләнгән квест белән «Остаздан дәрес» дип исемләнгән тематик мастер-класс та үтәчәк.

Алексей Созинов сүзләренә караганда, быел фестиваль шактый үзгәрешләр кичергән. Иң лаеклы дип табылган укучылар быел MED. STUD. WEEK исемле проектта да катнаша алачак. Студентлар белән бергә укучылар да студент тормышының тәмен татып караячак.

«Мондый чаралар абитуриентларга һөнәр сайларга, сайлаган юнәлешенең бөтен нечкәлекләрен аңларга ярдәм итә. Без университетны түгел, тармакны күрсәтәбез», – ди ректор.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СЫЕРЛЫ ТОРМЫШ СЫЙЛЫМЫ?

Кышын гадәттә шәхси хуҗалыкларда сөт күләме кими, ә бәясе арта. Узган еллар белән чагыштырганда, бәяләр бераз тотрыкланса да, терлек азыгын кыйммәт бәядән юнәтүне исәпкә алсаң, барыбер аз түлиләр, ди халык. Сөткә кайсы районнарда нинди хак куелган? Без шул хакта белештек.



КАЙБЕР РАЙОННАРДА СӨТ ҖЫЮНЫҢ УРТАЧА БӘЯЛӘРЕ

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдим иткән мәгълүматлар буенча, авыл халкыннан көн саен 533,6 тонна сөт җыела. Бүген республикада аның бер литры уртача 28,32 сумны тәшкил итә. Министрлыкта әйтүләренчә, бу – узган ел белән чагыштырганда 22,7 процентка күбрәк. Ләкин район белән район арасында аерма шактый зур. Әйтик, Балтач районында сөтнең бер литры өчен уртача 31 сумга якын акча түлиләр. Шул ук вакытта Кайбычта нибары 25 сум гына бирәләр.

– Халыктан иң күп сөтне дә балтачлылар җыя, – дип аңлаттылар Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында. – Алар тәүлеккә 78 тонна сөт җыеп тапшыра. Арчада бу күрсәткеч – 40, Кукмарада 40,1 тоннаны тәшкил итә.

Сөт бәясе – Кама Тамагы районының Олы Мәрәтхуҗа авылында яшәүче Айрат Кадыйровның да күңеленә тынгылык бирмәгән мәсьәлә.

– 16 гыйнварда сөт тапшыру бәясе 25 сумга төште, – дип шалтыратты ул редакциягә. – Бездә сыер асраучылар да бар. Җәй көне сөт бәясе 28 сумга менгән иде. Хәзерге 25 сум бик аз бит. Терлек асрау – бик чыгымлы да, мәшәкатьле дә эш. Халык аны рәхәтлектән тотмый лабаса. Бераз булса да файдасын күрәсе килә. Тик файдадан бигрәк, зыяны күбрәк. Бездә сөтне «Эко-продукт» оешмасы җыя. Безгә булса да халык мәнфәгатен кайгыртсыннар иде.

Республиканың Идел буе зонасындагы районнарда (Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Тәтеш, Яшел Үзән) халыктан җыела торган сөт бәяләре, башкалар белән чагыштырганда, бернигә ел рәттән арзанрак йөри. Шушы районнар арасында сөткә иң аз бәяне Чүпрәле районында түлиләр. Нибары 23,84 сум.

Ә бит Чүпрәледә халык мөгезле эре терлекләрне, шул исәптән сыерларны күпләп асрый. Әйтик, Иске Кәкерле җирлегендә 325 хуҗалык бар. Алар 600ләп тирәсе мөгезле эре терлек тота. Шуларның 180е – сыерлар. Җирлек башлыгы Рөстәм Фәткуллин әйтүенчә, авылда бер-ике генә сыер тотучылар саны аз. Кубесенчә җиде-сигез сыер асрыйлар. Узган ел авыл халкы 390 тонна сөт җыеп тапшырган.

– Сөт бәяләре түбән, дип халык зарлана, әлбәттә. Шул сәбәпле күпчелеге үзләре эшкәртеп сатарга тырыша. Эремчеген, корткын, маен, каймагын сата. Сөтнең өч литрын 150 сумнан бирәләр. Сөт җыючыга 23 сумнан тапшырылар иде, ә болай бер литры 50 сумга чыга. Яхшы бит. Иренмәгән, тырыш кеше файдасын күрә. Ризыкларын алып бетерел баралар. Авыл төркемнә язып кына торалар. Чөнки мал асрарга вакыты булмаган кешеләр, читтә эшләүчеләр, өлкәннәр күп авылда. Сөт ризыгын Ульянга илтеп сатучылар да бар. Без үзебез да сөтне күршеләрдән сатып алабыз. Эшкәртүдән калганын яки эшкәртер өчен вакыты җитеп бетмәгәннәр сөтне җыючыга тапшыра, билгеле, – диде Рөстәм Фәткуллин.

Республикада терлек саны иң күп булган районнарның берсе Чүпрәледә вазгыять ни өчен шундый соң? Әлеге сорауны районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Тәлгат Халитовка бирдек.

– Районда шәхси хуҗалыкларда 5200 баш сыер асрыйлар. Сез әйткән мәсьәлә – иң авыры, – дип көрсенде ул. – Хәзерге вакытта авыл җыеннары уза. Аларда да иң еш телгә ала торган сорау бу. Кая гына барсак та, халыкны шушы сорау кызыксындыра. Сөт бәяләре – район күрсәткечә дә ул. Бүген бу кеше сыерын чыгарып сата икән, иртәгә аңысын җитәкләп кайтмый инде.

Талгат Халитов әйтүенчә, сөт бәяләре түбән булуның төп сәбәбе – сөтнең кулдан-кулга күчүе. Әйтик, районда сөт җыючылар аларны сигез трейдерга тапшыра. Алары үз чиратында заводларга алып бара. Шулай итеп, баскыч никадәр күбрәк булган саен, сөт бәясе дә аска тәгәри һәм гади авыл апасы кулына аз гына күләмдә килеп ирешә.

– Районда сөт эшкәртү заводы юк. Әнә шунысы бик начар. «Исток» кооперативы үз эшен узган елның җәендә генә башлап җибәрде. Яңа трейдерлар белән эшләү җаен карарга, зуррак альтернативалар эзләргә кирәк. Күрше районнарда да бер төрле генә түгел бәя. Кайсыларында 1 сумга артык, кайсыларында 1 сумга ким. Апас трейдерлары килеп, безнең базардагы хәлне өйрәнә башлады. Алар да районның еракълыгын әйтәләр. Сөт җыючылар Әлмәткә кадәр илтә бит сөтне. Шуларның барысын да мескен крестьян җилкәсе күтәрергә тиеш булып чыга. Без дә күл кушырып утырмыйбыз инде. Төрле юлларын эзлибез, хәлне бик яхшы аңлыйбыз. Азык хәзерләүдә да ярдәм итәргә тырышабыз. Сөт бәясе түбән булу безгә дә яхшы түгел, – диде Тәлгат Халитов.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы вәкиле аңлатуынча, сөт бәяләре түбән булуның төп сәбәпләре – районның сөт тапшыру пунктларыннан еракта урнашуы, сөтне аз күләмдә тапшыру һәм халыктан җыела торган сөтнең сыйфаты тотрыклы булмау. Әлеге мәсьәләгә карата авыл хуҗалыгы министры Марат Җәббаров та берничә тапкыр үз фикерен әйтте. Аның сүзләренчә, кооперативлар булган җирда бу эш актив алып барыла. Терлек аз булган районнарда әлеге мәсьәләдә кыенрак, чөнки чыгымнар үз-үзен акламый. Кайдадыр – 80, кайдадыр 100 литр гына сөт булса, ташуга киткән чыгым арта.

– Без районнардагы сөт бәяләрен ай саен анализлыйбыз, күзәтәбез, тик билгеле бер бәядән төшерергә ярамый, дип йогынты ясый алмыйбыз, – дип аңлаттылар министрлыкта. – 24 кооператив сөт эшкәртү белән шөгыльләнә. Без аларга грантлар бирәбез.

Гомумән алганда, халык арасында мини-фермалар төзүгә бәйле программа иң популяры икән.

– Узган ел 107 шәхси хуҗалык 50 млн сум субсидия алды. Сигез сыер асраучы хуҗалыклар мини-ферма төзер өчен 600 мең сумга кадәр ярдәм ала, бу шулай ук сөтнең үзкыйммәтен кимәтә, – диделәр министрлыкта.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАН АФРОДИТАЛАРЫ

«МИСС ТАТАРСТАН» БӘЙГЕСЕННӘН СОҢ УЙЛАНУЛАР

Мөнәсәбәт

Матурлык ни белән үлчәнә? Толымнар калынлыгы, бот озынлыгы, бил нечкәлеге, акыл дәрәҗәсе беләнме? Бу сорауга җавапны «Мисс Татарстан» бәйгесе катнашучылары яхшы беләдер, мөгаен. Санап киткән сыйфатларга ия инде алар. Ия булмасалар, сәхнәгә чыкмаслар, тамашачы хозурына тәкъдим ителмәсләр дә иде.

Кешелекнең иң матур өлеше саналган затларны чибәрлек һәм буй-сын, тыйнаклык һәм зирәклектә сынаулар даими булып тора. Бөртектән кибәкне аеру, хатын-кызлар гүзәллеген бер калыпка салу, сокландыру – бәйгеләрнең максаты бу гына түгел дип ышанасы килә инде анысы. «Мисс Татарстан» дигәне нинди максатларга хезмәт итә икән соң? Туйлар узгач, тик кызларның башына кидерелгән таҗлары тузганчы, оештыручылар шул хакта бәян итте.

«Мисс Татарстан» президенты Изольда Сахарова чараны ярыш дип түгел, бәйрәм дип атарга куша әнә. Бәйрәмнең дә тамашачы өчен күзне иркәли, катнашучылар өчен үзеңне иң яхшысы итеп тою мөмкинлеге бирә торганы!

– Конкурсны чирек гасыр үткәреп киләбез. Быел аннан чын-чынлап бәйрәм ясарга теләдек. Шуңа күрә башка шәһәрләрдән дә гүзәл кызларны кунакка чакырдык, – диде Изольда Сахарова.

Шулай итеп, 30 чибәркәй урынына 50 кыз катнашкан булып чыга матурлык бәйрәмендә. Аңлашылганча, 20се – илнең башка төбәкләреннән килүчеләр. Әмма «Татарстан» сүзе кергән титулны башка шәһәр гүзәленә бирү мантыйк ягыннан дөрес булмас иде бит инде. Бездә матур кызлар беткәнме, дип тә уйлап куярга мөмкин ич кайберәүләр. Ә без кунакларны да күчтәнәчсез җибәрә торган халык түгел. Кунак катнашучыларга «Miss Beauty Fest» дигән номинация булдырганнар иде.

Юбилей булгач, зурдан кубасылары аңлашыла. Изольда Сахарова да яшерми: барысын да исеме җисеменә туры килерлек итеп оештырганнар.

– Киемнәребез дә затлы, бүләкләребез дә саллы. Быел җиңүче кызларыбызның өчесе дә 1әр миллион сум күләмдә акчалата приз алды. Финалда аларга бүтән бүләкләр дә күп булды. Аның кадәр күп бүләкләр бирә торган җирне табарга кирәк әле, – диде ул.

Матурлык конкурсы булгач, иң элек тышкы гүзәллекне күрсәтергә кирәк икәнен инкарь итеп булмый инде. «Татарстан интеллекты» дигән бәйге түгел ләбаса. Матурлыкны күлмәк белән дә, пальто белән дә, купальниктан да күрсәтү мөмкин. Финалга чыккан кызлар шулай киенгән дә. Бәйге дизайнеры Екатерина Тонюшкина әйтүенчә, кызлар кигән киемнәр мәгънәгә ия булган, һәр чыгыш өчен аерым кием-салым әзерләнгән. Мәгънә дигәнен тамашачы күреп өлгергәндер дип ышаныйк. Кызлар матурлыгы фикерләрне чуалтырга бик мөмкин югыйсә.

«Татар-информ»

Табигать күренешләрен дә киемгә күчерергә теләгәннәрен әйтте оештыручылар. Һәр киемгә 16 метр тукыма киткән, ди. Купальникларындагы күкрәк өлешләренә исә алтын-көмешләр дә йөгертелгән ди әле. Кызлар үзләрен әкиятләрдәге су кызы итеп хис итсен өчендер монысы. Матурлык, нәфислек дигәндә бу юлы агрессив кызыл төстән качканнар. Чарада алсу, ал, җылы төсләр генә хакимлек итте.

Әмма Изольда ханым кием-салымга киткән акчаны санамаска кушты, бәясен дә әйтмәде.

– Сезгә белгертү яклы түгел мин. «Бу бәйгедә бу модель 300 мең сум тора икән, монысында болай икән», – дию була аннары. Бу дөрес түгел. Алай бәяләргә кирәкми, – дип кенә кырт кисте ул. Каләм әһелләренең конкурсның матди ягына аеруча игътибарлы булуларына да шелтә белдерде. «Без – фәлсәфә, ә сез – акча турында», – дигән булды.

Фикер

Бу җәһәттән егетләрдән: «Матурлык конкурслары кирәкме? Чын матурлык нәрсә ул?» – дип сораштык.

Нияз РАХМАН, алып баручы:

– Андый конкурслар булырга тиеш. Тик менә җиңүчеләр генә гадел булсын инде. Күп очракта акча хәл итә бит. Моннан тыш анда катнашкан кызлар соңыннан «товар»га әйләнеп, начар юлга кереп китмәсеннәр иде. Матурлык янында – акча, ә акча күп булган урында бозыклык була. Бөтен кеше үзенчә матурдыр инде ул. Ә бүген хатын-кызлар үзләренә игътибарны социаль челтәрләрдә «лайк» белән җыя. Шәрә арт сан, зур күкрәкләр, кабартылган иреннәр заманасы. Күпләр, шуңа кызыгып, башларын югалта. Ә хатын- кызның матурлыгы тышкы якта гына түгел. Аның гүзәллеген әни булуы, гаиләнең учагын саклаучы, тормышта канатландырып торучы кеше булуында да күрә белергә кирәктер.

Искәндәр НУРМИЕВ,
7 нче шәһәр клиник хастаханәсе медицина хезмәткәре:

– Чибәрлек бәйгеләренә мөнәсәбәтем уңай. Һәр тармакта иң шәпләрен сайлау булырга тиеш. Шул ук медицина тармагында да «Ак чәчәкләр» дигәне бар бит. Матурлык минем өчен беренче урында тора. Әйтәләр инде, имеш, тышкы кыяфәт, чибәрлек роль уйнамый, дип. Кеше матур булмаса, ул сине кызыксындыра да алмый. Чын матурлыкны берничек тә, берни белән дә яшереп булмый. Ул яңгырлы көндәге кояш нуры кебек – бар җирдән балкып тора.

Аның әйтүенчә, бәйгедә матди кыйммәтләр түгел, дистә еллардан соң да мәгънәгә ия булырлык рухи, мәдәни кыйммәтләр барлыкка килә. Шулай буласына ышаныйк та аның әйткәннәрен вакыт хөкеменә калдырыйк соң.

Төп титулга исә Казан кызы Рамина Пронина лаек дип табылды. Чибәркәйгә әле – 20 генә яшь. Хәзер ул «Мисс Россия» бәйгесенә әзерләнә. Андагы халыкны ничек гаҗәпләндерергә җыенуларын сер итеп калдырды кыз. Татарстан исеменә тап төшермәсләр анысы.

– Безнең кызлар сөйкемле йөз, озын аяклар белән генә истә кала торган шәхесләр түгел. Алар эчке дөньяларының бай булуы белән аерылып тора. Физик таләпләр, әйе, мөһим. Тик алар гына җитми, – диде Изольда Сахарова да.

Ярар, без эчке дөньяларының ни дәрәҗәдә тирән булуын күрә алмадык инде. Тамашачы күргәндер. Шикләнергә хакыбыз юк: жюри да Татарстанның төп гүзәлен белеп сайлагандыр. Бу кыз бит башкалар өчен дә эталон һәм үрнәк санала хәзер.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың химия сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Нәфис Косметикс» акционер җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинаты (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) баш инженеры урынбасары **Алексеев** Владимир Тимофеевич; мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар сәясәте бүлеге башлыгы **Әмирова** Лилия Сәлимҗан кызы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе **Вәлиева** Сүрия Шаһит кызы, Казан шәһәре Киров районының «15 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Харисов** Фәнит Фахраз улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Агро-Мир» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең токым үрчетү буенча технологы (Татарстан Республикасының Ютазы районы) **Баязитова** Фәүзия Мөдәррис кызы, «Наратлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Латыйпов** Рәшит Әнвәр улы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Хәлиуллин** Рафак Шамил улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык хезмәтләре өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең оештыру эше бүлеге башлыгы урынбасары **Жирнова** Галина Ивановна, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең законнар мониторингы һәм коррупциягә каршы экспертиза секторы мөдире **Ишмаева** Эльвира Рим кызы; «Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте персоналга идарә дирекциясенең кадрлар бүлеге башлыгы **Нәкыйпова** Римма Бакый кызы; республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Лукоянова** Татьяна Михайловна, хезмәт ветераны **Смирнова** Наталья Николаевна; республиканың оборона сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе 3 номерлы участогының 8 номерлы цехы токаре **Синюгин** Александр Вячеславович; югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең философия һәм социаль-сәяси дисциплиналар кафедрасы профессоры **Хисаметдинов** Сәгыйть Рамазан улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Нәтиҗәле иҗади эшчәнлекләре һәм музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен вокалчы артист (солист) **Каһиров** Филүс Фәһим улына, «Казан шәһәр филармониясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең концерт бүлеге вокалчы артисты (солисты) **Шәйгәрдәнова** Алинә Наил кызына **«Татарстан Республикасының халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

Үзебезнең Зумба

ҖИР «АЛМА»СЫ ХИКМӘТЛӘРЕ

Бәрәңге үстерүнең ни икәнлеген бала чагымнан ук яхшы беләм дип йөрсәм дә, галим Фәния Җамалиева белән сөйләшкәндә, үзем өчен шактый күп яңалык ишеттем.

Баксаң, Татарстан җирләрендә икенче икмәк бары тик унсигезенче гасырда гына тарала башлый. Ерак илләрдән китерелгән бәрәңге безнең табигать шартларында тиз арада төрле чирләр белән зарарлана. Аны язга кадәр саклау да зур проблемага әйләнә. Бакчачылар алдына тиз арада безнең шартларга яраклаштырылган сортлар уйлап табу бурычы куела.

– Безнең шартларга яраклаштырылган бәрәңгенең яңа сортларын булдыру эшенә унсигезенче гасырның икенче яртысында бакчачы галим Ефим Грачев алына. Ул уйлап чыгарган сортларны Россиядә әле бүген дә уздыра алган галим юк. Гаҗәп, әмма факт: Ефим Грачев тарафыннан чыгарылган йөзгә якын сорт ул замандагы Халыкара күргәзмәләрдә 11 алтын, 41 көмеш һәм 11 бронза медаль яулаган. Бер генә бәла – фитофтора, халыкта «черү» дип аталган чир әлеге сортларның уңышын нык киметә. Бәрәңгене әлеге зарарлы микроблардан арындыру өчен озак елларга сузылган фәнни-тикшеренүләр шактый күләмдә матди чыгымнар сорый, – ди Татарстанның атказанган агрономы, узган гасырның сиксәненче елларыннан башлап, хәзерге көнгә кадәр бәрәңгене күпләп җитештерү белән шөгыльләнүче Россия күләмендә танылган галим Фәния Җамалиева.

Шактый еллар дәвамында күңелне тырнап торган сораулар: «Ни өчен без дистәләрчә еллар дәвамында орлыклык бәрәңгене шактый кыйммәт бәягә чит илләрдән сатып алабыз?», «Соңгы елларда Россиягә карата кертелгән төрле чикләүләр, санкцияләр нәтиҗәсендә, орлыклык бәрәңгене чит илләрдән сатып алу мөмкинлеге булмаса, бәрәңгене күпләп җитештерү күләме кимемәсме?»

Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының селекция һәм орлыкчылык үзәге җитәкчесе, биология фәннәре кандидаты Зенон Сташевски әйтүенчә, бәрәңгенең төрле авыруларга бирешми торган югары җитештерүчән яңа сортларын булдыру максатында 1985 елда махсус лаборатория төзелә. Шушы еллар эчендә Татарстан галимнәре тарафыннан бәрәңгенең төрле вирусларга бирешми торган өр-яңа сортлары уйлап чыгарыла. Аларның һәркайсы Россиянең төрле төбәкләрендә уңышлы сынау уза. Шундыйлардан Кортни, Регги, Танго, Самба, Зумба һәм Сальса дип аталучы сортлар, барлык төр сынауларны уңышлы үтеп, Россия Федерациясе Дәүләт теркәвеннән патент алуга ирешә. Әлеге сортлар Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан бәрәңге селекциясе казанышы дип таныла. Бүген ил кырларында сынау үтүче Догода, Орлан, Блоссом һәм Дана сортлары да якын киләчәктә күпләп җитештерелә башлар, шәт. Ә иң сөенечлесе: Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының селекция һәм орлыкчылык үзәгендә соңгы елларда бәрәңгенең утызга якын югары җитештерүчән яңа сортлары сынау уза.

Камил СӘГЪДӘТШИН


vk.com

ИЯСЕНӘ ӘЛӘКСЕН!

Нәтиҗә

Татарстанда 1 миллион 122 мең кеше пенсия ала. Узган ел беренче тапкыр 48 мең кешегә пенсия билгеләгәннәр. 2023 ел башыннан иминият пенсияләре 4,8 процентка индексацияләнде. 1 февральдән барлык төр социаль түләүләр (айлык акчалата түләү, социаль хезмәтләр җыелмасы, ана капиталы) 11,9 процентка артачак. 1 апрельдән исә социаль пенсияләр 3,3 процентка индексацияләнәчәк. Бу хакта Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлекчәсе идарәчесе Эдуард Вафин узган ел нәтиҗәләренә багышланган утырышта сөйләде.

Исегезгә төшерәбез: быелның 1 гыйнварыннан Россиянең Пенсия һәм Социаль иминиятләштерү фондлары берләшеп, бер оешмага әверелде. Социаль фондның Татарстан буенча бүлекчәсе утырышында бу вакыйга турында сүз күп булды. Җитәкчеләр тынычландыра: борчылырга кирәкми, зыяны булмаячак. Пенсияләр дә, социаль түләүләр дә, пособиеләр дә үзгәрми. Элек ничек булды, шулай дәвам итәчәк. Әле киресенчә, Социаль фонд аша дәүләт ярдәмен алу гадиләшәчәк. Элек берничә документ кирәк булса, хәзер бер гариза белән дә алып була.

Сүз дә юк, дәүләт ярдәменең күп өлеше бала үстерүче гаиләләргә кагыла. Утырышта быелның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән универсаль пособие турында сөйләделәр. Билгеле булганча, ул туганнан алып 17 яшькә кадәрге баласы булган гаиләләргә, шулай ук йөклелекнең иртә срогында медицина учреждениесендә исәпкә баскан хатын-кызларга түләнә. 1 февральдән исә ана капиталының да күләме артачак. Мондый акча түләнә башлаганнан бирле республикада аны 386 мең гаилә рәсмиләштергән. Аларның 86 проценты бу акчаны тулысынча тоткан. Аны капиталын күбрәк торак шартларын яхшырту өчен сарыф иткәннәр.

Пенсия билгеләүдә үзгәрешләр дә бар. Илдә махсус хәрби операция башлангач, анда катнашучыларга пенсияләрне башкача исәпли башлаганнар. Махсус хәрби операциядә катнашу вакыты ташламалы тәртиптә, ягъни икеләтә күләмдә исәпләнә. Чакырылыш буенча хезмәт итү вакыты хәзер махсус стажга кертелә.

Утырышта тернәкләндерү чаралары алу хакында сүз булды. 2022 елда физик мөмкинлеге чикле кешеләр 1,3 миллиард сумлык тернәкләндерү чаралары белән тәэмин ителгән. Инде язганыбыз да бар, хәзер кешеләр үзләренә кирәк-яракны электрон сертификат белән ала башлады. Моның өчен гариза язарга, үзеңә тиешле акчаны электрон рәвештә генә кулланырга була. Һәркем кирәкле тернәкләндерү чарасын сайлап ала. Узган ел республикада яшәүче 550 кеше бу хезмәттән файдаланган. Быел исә протезларны электрон сертификат ярдәмендә бирә башлыйлар.

Эдуард Вафин әйтүенчә, шифаханәләрдә дәвалану өчен 210 миллион сум акча бүлеп бирелгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– 7 меңнән артык кеше сәламәтлеген ныгытты, шуларның 805е – инвалид балалар. Бер меңгә якын юллама инвалид балаларны һәм 1 төркем инвалидларны озата баручыларга бүлеп бирелде. Хәзерге вакытта сәламәтлеген ныгытыр өчен 24 меңнән артык кеше чиратта тора, – диде идарәче.

Электрон дәүләт хезмәтләре хакында да сөйләштеләр. Баксаң, 2022 елда Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге тарафыннан 610 мең дәүләт хезмәтенең 76,2 проценты (465 мең) электрон формада күрсәтелгән. Социаль иминиятләштерү фондының төбәк бүлеге 2022 елда дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә 557 меңнән артык гариза кабул иткән, шуларның 490 меңнән артыгы электрон рәвештә алынган, бу барлык гаризаларның 88 процентын тәшкил итә икән.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева тармак хезмәткәрләренә кешеләрнең документлары белән эшләгәндә бик төгәл булырга киңәш итте. Әмма сүз башында ул, берләштерелгән ике фонд җитәкчесенә дә рәхмәтен җиткерде.

– Яңа фонд яңа бурычлар куя, – диде ул. – Шуңа да җирлекләрдә эшләүчеләр дә кирәкле язуларны төгәл һәм сыйфатлы итеп башкарырга тиеш. Алар биргән мәгълүматларга таянып эшлисе була бит. Берәү дә пенсия билгеләгәндә, тегеннән-моннан документ, стажын эзләмәсен. Моның бердәм системасын булдырырга кирәк.

Ләйлә Фазлыева эш урыннарында кешеләрнең сәламәтлеген саклауга да тукталды. Ана капиталы алучы имин булмаган гаиләләрне дә контрольдә тотарга кушты. Кыскасы, эшлисе эшләр күп, әмма башкарылганнары үрнәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Авыл язмалары

Марат КӘБИРОВ

Мул тормышта

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Тормыш кайный» дигән сүз бар бит… Кайнаган нәрсә урынында гына тормый ич ул, бер югарыга менә, бер түбән төшә. Тормыш та шулай. Без генә гел алга барадыр, гел үргә күтәреләдер кебек кабул итәбез. Шуңа үткәннәргә бераз өстәнрәк карыйбыз, ата-бабалар бездән наданрак, акылсызрак булгандыр, начар тормышта яшәгәндер, дип уйлыйбыз. Чынында хәлләр чүт кенә бүтәнчәрәк.

Авыл менә… Хәзер авыл тормышын да бик начар дип әйтеп булмый. Йортлар салып куялар – урап чыгарлык түгел. Газ белән җылытыла, суы өенә кергән, туалет-ваннасы да өй эчендә. Кайберәүләрнең мунчасы да йортына терәлеп тора хәтта. Эченә керсәң дә, читтән карасаң да, яңа төзелгән шундый йортлар әллә кайдан балкып, күзләрне сөендереп тора. Безнең авылда да шундый өйләр хәтсез генә. Татар ул тынгысыз бит инде, йорт-курасын ялт иттереп тотарга тырыша. Көн-төн эштә йөргәне дә үз дөньясын карарга вакытын да, көчен дә таба. Шулай казганып яши-яши дә көннәрнең берендә шундый балкып торган йорт-каралтысын калдырып, теге дөньяга китеп бара…

Көндез генә артык абайламыйсың икән… Урамга бер максатсыз гына чыкмыйсың ич инде, ә максатың булгач, шуның артыннан йөгерәсең, тирә-ягыңа каранып иркенләп йөрергә форсатың булмый. Алай итсәң дә, күзгә чалынмас иде. Ә кичләрен… Әле менә акрын гына атлап, эшен бетереп тугарылган ат шикелле, авыл урамы буйлап кайтып киләм. Таныш-белешләрнең йортларына күз салгалыйм. «Монда фәлән абзый яши иде бит әле», – дип, хатирәләргә дә бирелеп китәм. Һәрбер йорт янында диярлек тукталып уйланырлык, искә алырлык нәрсәләрем бар икән. Ул хатирәләрнең кайсы – балачак шуклыклары, кайсы – яшьлекнең ярсу хисләре, кайсы көндәлек мәшәкатьләргә бәйле. Гомер урамымда да авылныкындагы шикелле кичке вакыт булгач, алар кадерле дә, беркадәр моңсу да.

Менә монда балачак дустым яши… иде… Ничәнче сыйныфтадыр укыган вакытта шаярышып көрәшкәндә, ул минем кулны сындырган иде. Авыртмады. Хәтта сынган дип тә уйламадык. Мин шул көйгә чөгендер кәтмәнләп тә йөрдем әле. Хастаханәгә баргач кына: «Шартлап сынган бит, нигә шундук килмәдегез?» – дип, Уфага җибәрделәр. Шул дустым аркасында мин, шәһәргә барып, дөнья күреп кайттым. Ә дуслык сүрелмәде, ныгыды гына. Һәм аның соңгы көннәренә кадәр дәвам итте…

Ә бу йортта… Бер кыз яши иде. Чибәр инде шундый. 8 март алдыннан качып кына кереп, бәйрәм бүләге итеп верандадагы өстәлләрендә китап калдырып чыктым. Мәхәббәтне аңлаткан бик матур язуы да бар иде. Тик кыз бернәрсә дә сиздермәде. Берничек тә. Шулай булгач, мин дә суындым инде. Бозга әйләндем. Соңрак үзе елмаеп йөрсә дә, сер бирмәдем. Бер сүрелгәч, кабат кабыну кыен. Бәлки мөмкин дә түгелдер. Соңыннан белдем инде. «Иртәрәк әле аңа егетләр турында уйларга», – дип, әнисе теге китапны сандыгына алып куйган да оныткан… Килеп чыккан инде туйлар узгач… Моңсу бераз…

Бераз гына түгел икән… Әллә нинди җанга уелып кала торган сәер моңсулык ул. Күзләргә яшь булып тыгылмаса да, йөрәкне кысып ала да җибәрми, сулкылдатып суырган сыман итә. Урамнар тагы да караңгырак булып калгандай тоела, арка үзәге буйлап салкын йөгерә, беләкләргә каз йоны калкып чыга. Яктылык һәм җылылык эзләп, күкләргә карасаң да файда юк, андагы ай-йолдызларны күргәч, гамең тирәнәя генә, үзеңне бөтен галәмдә берүзең калгандай хис итәсең. Сәер инде шундый. Сәбәбен бераз соңрак аңладым: үлем кебек гади генә икән…

Шул йортларда яшәүчеләрнең күбесе я шәһәргә, я теге дөньяга китеп барган, кая китсәләр дә, кире кайтмаслар инде – өйләре хәзер буш тора. Тәрәзәләрендә утлары булмагач, капка алларында карлары көрәлмәгәч, күңелдә бушлык уяна, хатирәләр ятим калган кебек була. Ә син шул ятим истәлекләреңне җитәкләп, ялгызың атлыйсың. «Әйе шул, чынлап та шулай иде бит», – дип, аларны күтәреп алырлык, нәрсәдер өстәп җибәреп җан өрерлек кешеләр инде юк.

Утсыз тәрәзәләр бик күп икән. Урамнар да тып-тын. Парлап узган яшьләр бөтенләй юк. Ялгыз атлаганнары да яшьләр түгел. Монда яшәүчеләрнең иң яшь дигәне дә безнең чоргылар бугай. 40–50 тирәсендәгеләр. Шулай булгач, ул авыл ничек элекке кебек шау-гөр килеп торсын ди инде?! Элек кеше бераз кысынкырак яшәсә дә, өе тәбәнәк, тормышы авыррак булса да, авылның җаны бар иде. Ут уйнатып яши иде ул. Хәзер хаста булып затлы түшәктә яткан өлкән яшьтәге бай кеше кебегрәк тоела. Киләчәге билгесез.

Нишлисең инде. Яшәү дәрәҗәсен муллык кына билгеләми шул. Бай тормышта матур итеп яшәү өчен, кайвакыт, исән һәм сау-сәламәт булуың да кирәк.

ХЕЗМӘТНЕ ВАКЫТ БӘЯЛӘР

АЙДАР ФӘЙЗРАХМАНОВ ТУГАН КӨНЕ КОНЦЕРТЫНДА ЯҢА КИТАБЫН ТӘКЪДИМ ИТТЕ

Татар җыры үрнәге! Милләтнең асыл улы! Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов яраткан тамашачысын традиция буенча туган көне концертына җыйды. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә узган кичәдә танылган җырчының гомер юлы турында яңа китабы да тәкъдим ителде.

Кирилл Буздалов / Татар дәүләт филармониясе матбугат үзәге

«Юлын белгән арымас» китабында Айдар Фәйзрахмановның тормыш юлы, гаилә истәлекләре, иҗат дөньясындагы кызыклы вакыйгалар, шәхси фотосурәтләре урын алган. Ул мәшһүр җырчының татар халык җырларын таныту өчен меңләгән чакрым узып башкарган хезмәтен дә, тормыш фәлсәфәсен дә чагылдыра. Әлеге китапның бер өлешен автор тамашачыларга да бүләк итте.

Данлыклы җырчының туган көн концертына, бөтен залны тутырып, аның иҗатын хөрмәт итүче яраткан тамашачысы җыелган иде. Матур кичәдә моңлы җырлар, халык биюләре, милли музыка кораллары тавышы яңгырады. Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татарстан фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең дәртле чыгышлары залдагы беркемне дә битараф калдырмагандыр. Үзләре бии, җырлый, бер үк вакытта уен коралларында да уйныйлар! Айдар абый башкаруындагы эчтәлекле, тирән мәгънәле шигырьләр дә күпләрнең күңеленә үтеп керде. Концертта танылган җырчылар Филүс Каһиров, Сиринә Зәйнетдинова, Рөстәм Насыйбуллин, Илгиз Мөхетдинов, Айгөл Хәйри, Алинә Шәрипҗанова, Алинә һәм Азат Кәримовлар Айдар Фәйзрахманов көйгә салган җырларны башкарды. Кайбер җырлар беренче тапкыр яңгырады.

Тамашада китаптагы истәлекләр зур экранда күрсәтелеп барды. Җылы гаилә истәлекләрен, хатларны Тинчурин театры артистлары Резедә Сәлахова һәм Артем Пискунов укыды. Истәлекләрдән берничә өзек тәкъдим итик әле.

«Айдар Фәйзрахманов – җырчы, музыкант, оештыручы буларак – чын профессионал. Әгәр тормышыбызның һәр өлкәсендә үз вазыйфаларын профессионаллар башкарса, бу дөнья шактый камил булыр иде! Соңгы елларда Айдар Фәйзрахманов зур активлык белән җырлар иҗат итә башлады. Олыгайган көндә яшьләргә хас үҗәтлек белән нигә тотынды икән бу эшкә, дип уйлаучылар да бардыр… Хәер, нигә гаҗәпләнергә? Үзе – җырчы (әле нинди генә!), үзе – музыкант (халык көйләрен үз йөрәге аша кичергән зат, өстәвенә ансамбль үз кулында)… Эстраданың нинди хәлгә (әрсез үзешчәннәр баскан заман) калганын күрә торып, җырларыбызның, көй-моңнарыбызның киләчәгенә ничек битараф кала алсын ул! Бу өлкәдә хәл кадәри үзеннән өлеш кертергә теләве дип аңлыйм мин аның җырлар язуын. Хезмәтенең асылын вакыт бәяләр», – дип язган Айдар Фәйзрахманов турында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин.

Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев фикеренчә, Айдар Фәйзрахманов музыка мәктәбендә яисә консерваториядә генә татарча җырларга өйрәнгән кеше түгел, татар аһәңе аның күңеленә бишек җырлары, кичке уен, аулак өй, Сабантуй моңнары аша балачакта ук иңгән.

Ул болай дип яза: «Хәтта милләтсез Опера театры да аны тулаем Европа кысаларына куып кертә алмаган. Ә инде 2002 елда фольклор музыкасы ансамблен җитәкләп, тора-бара университет профессоры дәрәҗәсенә җиткәндә, ул инде татар җыры, татар моңы сагында торучы, аны табып-туплап, эшкәртеп, халыкның үзенә кире кайтаручы «Оста»га һәм «Остаз»га әверелә. Фольклор ансамбле репертуарындагы һәр җыр, борынгы яисә бүгенге булуына карамастан, татар милли музыкасының чын үрнәге, эталоны дәрәҗәсендә башкарыла».

Тамашачылар арасында «Күчтәнәч» тапшыруын алып баручы Әлфинур Хисамова да бар иде. Ул «Юлын белгән арымас» китабын сәнгать дөньясында киләчәк буынга калачак алтын мирас дип атады.

– Айдарның моңарчы да шактый китаплары басылды. Монысы алар арасында – иң күләмле, аның бөтен язмышы, яшәеше, матурлыгы белән бик бай булып чыккан. Айдар Фәйзрахманов язмышы гына түгел, егерменче гасыр кешеләренең, безнең халыкның яшәеше турында бу китап. Айдарның дөньясы безнең өчен бик таныш. Ни өчен дигәндә, без нәкъ шул чорда, нәкъ шундый тәрбиядә үстек. Шуның белән кадерле дә ул. Автор-төзүче, мөхәррир Гөлинә Гыймадова эшен дә билгеләп үтмичә булмый. Китап искитмәле матур, затлы килеп чыккан, – дип сөйләде ул безгә. – Айдар Фәйзрахманов концертлары ул инде – чын сәнгать әсәре. Мин аларны Татар фольклор ансамбле оешканнан бирле карап киләм. Татар концерты нинди булырга тиеш, дигәндә, Айдар Фәйзрахмановныкын үрнәккә китерергә була. Үзе заманча, үзе бик затлы тамаша. Айдарның ансамбле искиткеч. Яшьләр белән эшләү, аларны тәрбияләү зур тырышлык, көч таләп итә. Егетләр-кызлар үзләре дә Айдарга әтиләренә караган кебек карый. Концерттан мин чын мәгънәсендә татар булуыма горурланып, безнең халыкның тәрбиясенә, моңына, матурлыгына сокланып кайттым. Анда бит бер генә нәрсә дә уйланмыйча эшләнмәгән. Айдарның әле алда никадәр тормышка ашырасы эшләре бар. Сәламәтлеге булып, шул хыяллары чынга ашсын иде, дип кенә телисе кала.

Кичәдә булган Илдус Хатыйпов та, Айдар Фәйзрахманов концертларын караган саен карыйсы килә, дигән фикердә:

– Айдар абый – мәңге үзгәрми торган шәхесләрнең берсе. Талантлы кеше һәр нәрсәдә дә талантлы була, диләр бит әле. Бу сүзләр нәкъ аның турында. Үзе җырлый, баянда уйный, бии, төс-кыяфәте дә егетләрчә. Без – Зөһрә Сәхәбиева, Хәйдәр Бигичев, Айдар Фәйзрахмановны тыңлап үскән буын. Айдар абыйның «Чаба поезд, чаба» дигән җырын аеруча яратып тыңлый, үзебез дә җырлый идек. Ул – гади җырчы гына түгел, иҗаты белән, татар мәдәниятен, моңын саклауга зур өлеш керткән, халык өчен чын күңелдән тырыша торган талантлы шәхес. Тормышы җиңел булмаса да, үзендә көч табып, тамашачы алдына чыгып, аның күңеленә үтеп керә белә торган чын моң иясе. Айдар Фәйзрахмановның фольклор ансамбле репертуарын, һичшиксез, мәктәп программасына кертергә кирәк. Татар теленә мәхәббәтне мәдәният аркылы гына арттырып була.

Ләйсән САФИНА

ТЕЛӘК БУЛГАНДА, БЕЛӘК КАРЫШМЫЙ

«Ир генә булып туасың калган!» Әгерҗе районы Кадыбаш авылында яшәүче 64 яшьлек Гөлфидә Камаловага кайчак шундый сүзләрне дә ишетергә туры килә. Чыгарган мичләренең санын хәтерләми: 100ләп үк юктыр, ди. Авылда ул чыгарган мичләр аз түгел.

Элек авылларда мич чыгаручының килүен кичтән үк әзерләнеп, зурлап көтәләр иде. Көтәрсең дә, мич – өйнең җылы чыганагы бит ул. Икмәген, бәлешен, коймагын пешерсәң дә, шул кирәк. Казанында суын кайнатасың. Гадәттә ул, оста дигәнең, берәр олырак яшьтәге абзый була. Ә Кадыбашта исә ул – хатын-кыз. Өйрәнчек дип түгел, булдыра дип ышанып каршы алганнар Гөлфидәне. Беренче мичен 24 яшьтә үк чыгарган икән. Кирпеч, измә эшенә рәхәтлектән түгел, акча җитмәгәнгә тотынган яшь килен. Мичче булып китү яки кемнедер шаккатыру теләге дә булмаган анда. Беренче ире белән яшәгәндә, иске мунча мичен сүтеп, яңаны чыгарырга тәвәккәлли. Бу эшне азмы-күпме белгән күршесен, әнисенең ахирәте Факия апасын киңәш-табышка чакыра. Алар өйдә гәпләшә-гәпләшә чәй эчкәндә, Гөлфидә, тирләп-пешеп, кирпеч өя. Факия апасы ара-тирә мунчага килеп: «Дөрес эшлисең!» – дип мактап киткәли. Ире әллә ни шаккатмаса да, Гөлфидә үзенең көченә сөенә, әлбәттә. Эшчән хатынга ялкау ир белән гомер итү җиңел булмый. Беренче никахыннан уңмый, кыскасы. Аерылып кайтып, әнисе янында 12 ел яши. Авылда исә ул клуб мөдире дә, фермада учетчик, амбарда ашлык үлчәүче дә булып эшләгән. Икенче мәртәбә гаилә коргач, теге шөгыленең тагын кирәге чыга. Бу юлы инде зурдан кубып, өйнекен чыгара. Ике каенанасын да, туган нигезен дә яңа мичле иткән ул. Шуннан инде осталыгын күреп, башка авылдашлары да чакыра башлый. Кирпеч, измә ташучылар булганда, эшне тиз тота. Бу эштә балалары булышкан. Олы йөрәкле әни ул! Үзенең өч баласы янына иренең өч баласын да сыендырган. Алар инде кайсы кая таралышкан. Төп йортта Гөлфидә апа ире белән гомер кичерә.

– Һәр эшнең рәте бар. Мич чыгарганда, беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәргә кирәк? – дип сорадым Гөлфидә ападан.

– Мич чыгаруның үз җае бар. Дөрес чыгармасаң, төтен тарта торган була. Ә бу синең бөтен эшеңне юкка чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә моржа юлларын дөрес билгеләргә, өйдә җылылык озак саклануга игътибар итәргә кирәк. Безнең авылга күрше авылдан бер абый мич чыгарырга килгән иде. Мин шуның эшен җентекләп карап тордым. Киңәшләрен дәфтәргә язып бардым. Кулдан тотып берәү дә өйрәтмәде, – ди мичче ханым.

Гөлфидә апа беренче вакытта мичләрне 3–4 көн буе өйсә, остарып киткәч, бер-ике көн дә җитә аңа. Кеше ниндине куша, шундыйны ясый. Кемгәдер зуры, кемгәдер плитәлесе кирәк. Газ кертелгәч, тагын башкача дигәндәй. Бер мич өчен 2–2,5 мең сум акча ала торган булган. Соңгы елларда мич чыгарып йөрергә вакыты юк икән. Малларыбыз күп, ди. Шулай да улы белән күрше авылга барып, берәүгә чыгарып кайтканнар әле. Белгән эшнең кирәге чыга аның.

Сәрия МИФТАХОВА

МИЧ КОЙМАГЫ

Ярты литр сөт һәм җылымса суга 5 йомырка сытасың, 1 аш кашыгы тигез генә итеп тоз, 5 аш кашыгы шикәр комы, 100 грамм үсемлек мае, 35 грамм чи чүпрә салып, камыр туглыйсың. Берничә мәртәбә кабартып, калак белән төшерәсең. Кабат күпереп менгәч, эшкә тотынырга була.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 215

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+